ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«УРМЫШЛИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ОРМЫШЛЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

« 12 » февраль 2021 ел № 4

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Ормышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2019 елның 29 октябрендәге 19 номерлы карары белән расланган агач һәм куаклар кисүгә, кронлауга яки утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 15 апрелендәге «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан яңа редакциядә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 601 номерлы карары нигезендә, «Ормышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Ормышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2019 елның 29 октябрендәге 19 номерлы карары белән расланган агач һәм куаклар кисүгә, кронлауга яки утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләрне кертергә:

2.6 пунктны түбәндәге эчтәлекле 2 подпункт белән тулыландырырга:

«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында мәгълүматлар- Россия ФСХ. Мәгълүматлар авария хәлләренә бәйле очраклар өчен бирелми»;

2.8 пунктны түбәндәге эчтәлекле 4 пункт белән тулыландырырга:

«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булу.»;

3.4.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 2 абзац белән тулыландырырга:

«законнарны бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурычлар булу (булмау) турында белешмәләр.»

2 һәм 3 абзацларны 3 һәм 4 абзацлар дип санарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Ормышлы авылы, Центральная урамы, 4 йорт, Яңа Елхово авылы , Родничная урамы, 22 йорт, Бохар авылы, Авангардная урамы, 23 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (leninogorsk.tatar.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Ормышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы А.Ф.Хәбибуллин